
Мордовия матбугат йортында әлеге теманы яктырткан брифинг vтте. Регионыбыз халкына җәйге чорда топ куркынычсызлык кагыйдәләрен искә тошерделәр.
Җәйге чорда республиканын су объектларында сәламәтлек куркынычсызлыгын һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итv бурычы аеруча актуаль. Шуна журналистлар белән РМ буенча Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын Баш идарәсе һәм Мордовиянен урман, аучылык хужалыгы һәм табигатьтән файдалану министрлыгы вәкилләре очрашты.

Республика территориясендәге урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итv турында Мордовия Республикасы Урман, аучылык хужалыгы һәм табигатьтән файдалану министрлыгынын урманнарны сак лау, яклау һәм янадан торгызу бvлеге житәкчесе (начальник отдела охраны, защиты и воспроизводства лесов Министерства лесного, охотничьего хозяйства и природопользования Республики Мордовия ) Евгений Чешуин сойләде. Ул Мордовия Республикасы Хокvмәтенен 08.05.2026 елдагы 481 карары белән республикада 2026 елнын 9 маеннан 2026 елнын 30 сентябренә кадәр янгынга каршы махсус режим кертелvен искәртте.
Мордовия территориясендә янгын куркынычы сезоны дәвамында урманнарда янгын куркынычын мониторинглаунын оч дәрәжәле системасы кулланыла - бу жир осте патруле, видеокvзәтv камералары ярдәмендә урман янгыннарын видеомониторинглау системасы һәм космик мониторинг. Агымдагы ел башыннан космик мониторинг ярдәмендә 6 термонокта (термоточка) табылган- аларнын барысы да тикшерелгән һәм эшкәртелгән.
- Мордовия Республикасынын барлык тобәк Урман хужалыгы диспетчерлык хезмәте хәбәрләрне тәvлек буе кабул итә. Республика тер-риториясендә барлыгы 12 урман янгыннары станциясе урнашкан. 2026 елда жәлеп ителvче кочләр саны узган ел белән чагыштырганда 56% ка, янгын сvндерv чаралары - 27% ка арткан. Янгын сvндерv техникасынын гомуми саны 386 берәмлек тәшкил итә,- дип билгеләп vтте Евгений Чешуин.  Урман хужалыгы министрлыгы, урман байлыгыбызны саклау очен, даими рәвештә профилактик эш алып бара һәм янгынга каршы пропаганда алып бара.
- Янгынга каршы махсус режим шартларында урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган очен штрафлар тvбәндәгечә: гражданнарга - 40-50 мен сум, вазыйфаи затларга - 60-90 мен сум, юридик затларга 600-1 миллион сум тәшкил итә. Гражданнарнын урманнарда булу һәм анда транспорт чаралары керv чикләvләрен бозган очен: гражданнарга - 1 меннән 3 мен сумга кадәр; вазыйфаи затларга - 10 меннән 30 мен сумга кадәр; юридик затларга 50 меннән 200 мен сумга кадәр штраф салына», - дип искәртте тобәк министрлыгы вәкиле.
РМ буенча Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын Баш идарәсе ГИМС vзәгенен Кече суднолар буенча дәvләт инспекторы (Государственный инспектор по маломерным

судам Центра ГИМС ГУ МЧС России по РМ) Александр Романов билгеләп vткәнчә, нәкъ менә су коену сезоны вакытында судагы барлык һәлакәтләрнен 80% тан артыгы була. Оператив мәгълvматларга караганда, агымдагы елда республика сулыкларында 4 суда бату очрагы булган инде. Дәvләт инспекторы судагы бәхетсезлек очракларынын төп сәбәпләре арасында халыкнын куркынычсызлык культурасынын тv-бән булуын, жиһазландырылмаган һәм тыелган урыннарда коенуны, балаларнын йозv кvнекмәләре булмавын, ата - аналарнын контрольсез булуын билгеләп vтте. Балаларны, хәтта алар йозә белсәләр дә, даими контрольдә тотарга кирәк, дип кисәтте ул. Балаларны чит кешеләргә һәм исерек кешеләргә ышанырга ярамый.
- Балаларны йозәргә ойрәтергә кирәк, моны беренче чиратта ата-аналар, бассейннар булган мәктәп, спорт һәм башка оешмалар эшләргә тиеш. Кечкенә балаларга сулыкларда индивидуаль коткару чаралары - жинсәләр, жилетлар һәм башкаларны сатып алырга кирәк, - дип сойләде Александр Романов.
Хәзерге вакытта Мордовиядә 10 пляж теркәлгән һәм ачылган, шул исәптән 2се шәһәр читендәге балалар сәламәтләндерv лагерьларында. Коткару постлары эшли торган һәм йозә белмәvчеләр очен сай су участоклары булган рохсәт ителгән, жиһазландырылган урыннарда су коенырга кинәш ителә. Шулай ук топ кагыйдәләрнен берсе - исерек хәлдә коенуны тыю. Мордовиядә иминлекне тәэмин итv максатларында халык һәм бигрәк тә балалар белән профилактик эшкә зур игътибар бирелә. Су объектларында куркынычсызлык һәм балаларны йозv буенча әзерләvне оештыру мәсьәләләре Мордовия Главасы Артём Здунов контролендә. Жәйге каникуллар башлану белән мәктәп яны лагерьларында планлы дәресләр оештырылды, барлык районнарда су объектларында ял итv урыннарындагы хәлне контрольдә тоту очен ОМС, МЧС вәкилләре, полиция һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләреннән торган мобиль торкемнәр эшли. «Балалар суда» акциясе кысаларында балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр белән берлектә даими рәвештә рейдлар vткәрелә. «
- Сулыкларда куркынычсызлык чараларын һәм vз-vзенне тоту кагыйдәләрен бозган очен административ жаваплылык каралуын истә тотарга кирәк. Суда куркынычсызлык билгеләре куелган урыннарда су коену» су коену тыела, су коенучыларны кече суднолардан, причаллардан һәм кvперләрдән суга сикерv кисәтv яисә административ штраф салуга китерә. Шулай ук исерек хәлдә коенган очен, балигъ булмаганнарга йозv очен каралмаган әйберләрне һәм чараларны куллануга юл куйган очен, шулай ук балигъ булмаганнарны, су объектларында йозv кvнекмәләре булуга карамастан, караусыз калдырган очен административ штраф салына, - дип ассызыклады Россиянен Мордовия буенча гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкиле.
Спикерлар искә тошергәнчә, бары тик уртак коч белән генә сулыкларда һәм янгыннарда һәлакәтләр санын киметvгә ирешеп була.

**Наилә НАСЫРОВА**